СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гагарина, д.29, с.Куюк-Ерыкса,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Гагарин ур., 29 нче йорт, Көек-Ерыкса авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-67-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** — **РЕШЕНИЕ**

№ 4-31 — 27 декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы N 1-6 карары белән расланган Көек Ерыкса авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2023 елның 11 декабрендәге № 02-01-19-2023 номерлы прокурор тәкъдиме, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Көек Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы N 1-6 карары (алга таба-Карар) белән расланган Көек Ерыкса авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның 5.6. пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.2. Карарның 5.10 пунктның икенче абзацын үз көчен югалтты дип танырга;

1.3. 5.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.13. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турындагы карар, «Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясындагы 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чины бирү хакында тәкъдим барлык кирәкле документлар белән бергә җирле үзидарәнең класс чиннары бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына кергән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru)

урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгы Ф.Р.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Көек Ерыкса
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Р.Шәйхетдинов